**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**«22» октябрь 2025 ел** **№ 10**

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль хезмәте турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 18 июнендәге 219 номерлы Нурлат муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 03 октябрендәге 66 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2019 елның 18 июнендәге 219 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (2019 елның 10 июнендәге 240 номерлы, 2020 елның 19 августындагы 301 номерлы, 2020 елның 16 октябрендәге 19 номерлы, 2021 елның 03 декабрендәге 88 номерлы, 2023 елның 09 августындагы 184 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6нчы “Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре” бүлегенең 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә::

1) Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә::

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу – вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен; югары белем яки урта һөнәри белем булу – авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел

эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.»

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Советының законлылыкны һәм хокук тәртибен саклау буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев